**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СЕЛО-АЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Алат, ул. Первомайская, 32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алат авылы, Первомайская ур., 32

**тел./факс 8(84365) 63-2-25, e-mail:Salat.Vsg@tatar.ru**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**06 февраль 2026 ел.** **№ 11**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл-Алат авыл җирлеге Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы авыл-Алат авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2022 елның 22 мартындагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау районы прокуратурасының 01.10.2025 № 02-08-01-2025/Прдп373-25-20920014 протестын үтәү йөзеннән Биектау муниципаль районы авыл-Алат авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл-Алат авыл җирлеге Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы авыл-Алат авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2022 елның 22 мартындагы 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлек 1.2 пунктының 10 абзацында «әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «гаризалы " сүзенә алмаштырырга»;

1.2. 2.3 бүлегенең 2.3.2 пунктында «берләштерелергә мөмкин» сүзләрен «берләштерелә»сүзенә алмаштырырга;

1.3. 2.4 бүлекнең 2.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы:

- гариза кәгазьдә бирелгән очракта-гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

- электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта-гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Муниципаль хезмәтне алдан кисәтү (проактив) режимда күрсәткән очракта-регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткән көннән алып 3 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән соң икенче көнгә

исәпләнә башлый".

2. Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча әлеге карарны халыкка җиткерергә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Башкарма комитет җитәкчесе
Алат авыл җирлеге Р.Р.Хакимуллин